ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 5 өлешендә “тиешле вазыйфаи төркемнәрнең” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 25 статьяда:
а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3. Муниципаль хезмәткәргә еллык түләүле төп отпуск 30 календарь көн дәвамлылыгында бирелә.”;
б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“4. Муниципаль хезмәткәргә еллык түләүле өстәмә отпусклар тиешле еллар эшләгән өчен, шулай ук федераль законнарда һәм әлеге Кодекста каралган очракларда бирелә. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен еллык түләүле өстәмә отпускның дәвамлылыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән чыгып санала. Еллык түләүле төп отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык түләүле өстәмә отпускның гомуми дәвамлылыгы 40 календарь көннән артмаска тиеш. Нормалаштырылмаган эш көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган эш көне өчен өч календарь көн дәвамлылыгында еллык түләүле өстәмә отпуск бирелә. Нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен еллык түләүле өстәмә отпуск, шулай ук федераль законда каралган башка очракларда бирелә торган еллык түләүле өстәмә отпусклар әлеге өлештә

каралган еллык түләүле төп отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык түләүле өстәмә отпускның гомуми дәвамлылыгына өстәп бирелә.”.

**2 статья**

1. “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 1 маендагы 90-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль закон) үз көченә кергән көнгә файдаланылмый калган еллык түләүле отпусклары яисә бу отпускларның бер өлеше булган муниципаль хезмәткәрләрнең аларны алу хокукын, шулай ук файдаланылмый калган еллык түләүле отпусклар яисә бу отпускларның бер өлеше өчен акчалата компенсация алу хокукын саклап калырга.

2. “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль закон үз көченә кергән көнгә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган еллык түләүле отпускларның дәвамлылыгын, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясы (“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль закон редакциясендә) һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 25 статьясы (әлеге Закон редакциясендә) таләпләренә туры китереп, аларның яңа хезмәт елыннан башлап санарга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 05 июль
№ 45-ТРЗ